Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Глазово авыл җирлеге
Үрнәк-Күмәк авылында гражданнар җыены
КАРАРЫ

2021 елның 20 ноябре № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Үрнәк-Күмәк авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 20 ноябрендә 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлеге Үрнәк-Күмәк авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- юлларны кардан чистарту;
җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр оештыру:
- зиратка контейнер сатып алу;
җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә:
- су насосы сатып алу ;
- езеклекләрне бетерү;
җирлек торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:
- минерализацияләнгән полосаны тезекләндерү

«ӘЙЕ» «ЮК».

соравы буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Халык җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 157 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 94 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучылар бертавыштан «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирделәр.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Үрнәк-Күмәк авылында гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлеге составына керүче Үрнәк-Күмәк авылында гражданнар җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен дерес дип танырга.

2. 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр

балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- юлларны кардан чистарту;

җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр оештыру:

- зиратка контейнер сатып алу;

җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә:

- су насосы сатып алу ;
- өзеклекләрне бетерү;

җирлек торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

- минерализацияләнгән полосаны төзекләндерү карарын кабул ителгән, дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Үрнәк-Күмәк авылы, Мәктәп урамы, 3а йорт, Глазово авылы, Заречная урамы, 13, Үрнәк-Күмәк авылы, Горький урамы, 19а адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Глазово авыл җирлеге башлыгы Н.К.Карабаева